Кем табар, ташка кадак кагар.
Нәрсә- энә белән кое казу.
Ачу хәтәр, ачудан нәрсә хәтәр.
Нинди тормыш тилмертә, җиңел тормыш тилертә.
... чәчсәң, шуны урырсың.
Татарга кем кирәкми.
Кем сүзе бер булыр.

Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса,
Татар теле бит ул татар белән
Аңлашырга ярый ...

# Туган тел турында

21 нче февраль

–

Халыкара

туган тел көне.

1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте

Беренче мәртәбә ул 2000 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

**ЮНЕСКО** (UNESCO —
The **U**nited **N**ations **E**ducational, **S**cientific and **C**ultural **O**rganization) — Организация Объединённых Наций по вопросам образования, науки и культуры.
Ягъни, Мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча
Берләшкән Милләтләр Оешмасы

ЮНЕСКО Халыкара Туган тел көнен билгеләп үтүне хуплап чыга. Чөнки бу оешма дөнья халыкларының матди булмаган мирасын саклау өчен көрәшә, традицион яисә халык музыкасын, биюләрен, гореф-гадәт һәм йолаларны, авыз иҗатын һәм җирле халыкларның туган телләрен саклап калу буенча зур эшчәнлек алып бара.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд. кеше сөйләшә, инглиз телендә — 478 млн, һинд телендә — 437 млн, испанда — 392 млн, рус телендә — 284 млн, гарәптә — 225 млн, португалия телендә— 184 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

# Күп телләргә бету куркынычы яный.

Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз, чөнки ул инде башка телдә сөйләшә башлый, шул телдәге мәгълүматны үзләштерә, ә аның үз бабаларының йөзләрчә ел үсеп-формалашып килгән мәдәнияте тел белән бергә юкка чыга.

Татар һәм рус телләре – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу телләре дип саналган 14 телләр арасында исәпләнә.

Хәсән Туфан. Туган тел. Укый
Миңнегулов Айдар.
Илдус Гыйләҗев. Туган тел. Укый
Галиева Зөлфия.
Сәлисә Гәрәева. Туган телем. Укый
Гыйздәтуллина Назлыгөл.
Нажар Нәжми. Татар теле. Укый
Закирҗанова Рушания.